ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

1 июль, 2024 ел № 34/7

Шәһәр Советының «Аерым муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 27 апрелендәге 24/7 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмнәрен арттыру һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 29 апрелендәге 287 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең хезмәт өчен түләве бердәм тариф челтәре нигезендә исәплəп чыгарыла торган хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 6 маендагы 300 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 31 декабрендәге 1097 номерлы карары белән расланган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәт-тән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 13 маендагы 321 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген

характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль учреждениеләр хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 10 маендагы 315 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 27 апрелендәге 24/7 номерлы Карарының 1 нче кушымтасына (Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/8, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/10, 2019 елның 23 маендагы 31/6, 2020 елның 6 февралендәге 36/5, 2020 елның 23 сентябрендәге 1/13, 2020 елның 17 ноябрендәге 2/3, 2021 елның 16 февралендәге 5/7, 2021 елның 27 декабрендәге 11/6, 2022 елның 25 февралендәге 13/8, 2022 елның 13 апрелендәге 14/7, 2022 елның 11 ноябрендәге 17/6, 2022 елның 26 декабрендәге 19/3 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Бердәм тариф челтәренең учреждениеләр хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлар):

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 19 242 |
| 2 | 1,0126 | 19 484 |
| 3 | 1,0256 | 19 735 |
| 4 | 1,0381 | 19 975 |
| 5 | 1,0521 | 20 245 |
| 6 | 1,0656 | 20 504 |
| 7 | 1,0802 | 20 785 |
| 8 | 1,0942 | 21 055 |
| 9 | 1,1083 | 21 326 |
| 10 | 1,1233 | 21 615 |

| | | |
|---|---|---|
| 11 | 1,1379 | 21 895» |
| 12 | 1,1535 | 22 196 |
| 13 | 1,1691 | 22 496 |
| 14 | 1,1846 | 22 794 |
| 15 | 1,2008 | 23 106 |
| 16 | 1,2174 | 23 425 |
| 17 | 1,2340 | 23 745 |
| 18 | 1,2512 | 24 076 |

Искәрмә. Җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (окладды) күләме җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1 - 2 разрядка түбәнрәк итеп билгеләнә.»;

2) 13 пунктта:

- «19 862,00» саннарын «25 014,00» саннарына алыштырырга;
- «15 279,00» саннарын «19 242,00» саннарына алыштырырга;

3) 15.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15.2. Аерым категория учреждение хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары 1 таблицада китерелгән:

1 таблица

Аерым категория учреждение хезмәткәрләренең
вазыйфаи окладлары

| Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад күләме (сум) |
|---|---|
| Җитәкче | 31 239 |
| Баш бухгалтер | 21 868 |
| Каравыл башлыгы | 26 108 |
| Янгын сүндерү бүлеге командиры | 25 191 |
| Янгын сүндерү машинасы йөртүчесе | 22 519». |

4) 17 пунктта «12 688» саннарын «13 323» саннарына алыштырырга;

5) 19 пунктның 5 пунктчасында «унбиш» сүзен «утыз җиде» сүзләренә алыштырырга;

6) 21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. «Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләрен финанслау үзәге» Муниципаль бюджет учреждениесеннән тыш, аерым оешмалар җитәкчеләренең, бел-

гечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган арттыру коэффициентлары һәм вазыйфаи окладлар күләме:

| Вазыйфа исеме | Арттыру коэффициенты | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| Оешма җитәкчесе | 2,25 | 29 977 |
| Оешма җитәкчесе урынбасары | 2,0 | 26 646 |
| Бүлек башлыгы | 1,65 | 21 983 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1,55 | 20 651 |
| Баш белгеч | 1,4 | 18 653 |
| Әйдәүче белгеч | 1,17 | 15 588 |
| I категорияле белгеч | 1,12 | 14 922 |
| II категорияле белгеч | 1,1 | 14 656 |
| Белгеч | 1,08 | 14 389»; |

7) 21.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21.1. «Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләрен финанслау үзәге» Муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме:

| Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|
| Җитәкче | 33 177 |
| Җитәкченең беренче урынбасары; җитәкче урынбасары | 31 268 |
| Бүлек башлыгы | 24 465 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 22 020 |
| Баш белгеч | 20 050 |
| Әйдәүче белгеч | 18 260»; |

8) 21.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21.2 Аерым муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган арттыру коэффициенты:

| Вазыйфа исеме | Коэффициент | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| Архив мөдире, өлкән инспектор, машинкада басу бюросы мөдире, күчермәләр ясау - күбәйтү бюросы мөдире, инспектор, статистик, хуҗалык мөдире, склад мөдире, кассир, комендант, эш башкаручы, архивариус, стенографист, секретарь-стенографист, машинистка, экспедитор, секретарь-машинистка, җитәкче секретаре, таксировщик, участок мастеры (шул исәптән өлкән мастер) | 1,0 | 13 323»; |

9) 22 пунктның 3 пунктчасында «унбиш» сүзен «утыз җиде» сүзләренә алыштырырга;

2. Әлеге Карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев